**10-11нче сыйныфларда**

**“Туган тел (татар теле)” предметын укыту буенча программа**

Мәктәбебездә урта (тулы) гомуми белем бирү баскычында татар теле предметын укытуга 68 сәгать билгеләнә: X сыйныфта атнага 1 сәгать исәбеннән елга 34 сәгать; XI сыйныфта шулай ук атнага 1 сәгать, елга 34 сәгать.

Югары баскычта рус телле балаларга татар теле укыту максатлары берничә аспектны үз эченә ала: белем бирү, танып белү, үстерү, тәрбия.

**Белем бирү:**

- коммуникатив компетенция, татар телендә сөйләшүчеләр белән телдән яки язмача аралашу күнекмәләре булдыру: коммуникатив бурычлар куя һәм хәл итә белү;

- адекват рәвештә аралашуның вербаль һәм вербаль булмаган чараларыннан, сөйләм этикеты үрнәкләреннән файдалана алу, итәгатьле һәм киң күңелле әңгәмәдәш булу.

Укучылар 1-9 нчы сыйныфларда алган белемнәрен тагын да тулыландыралар, киңәйтәләр, гомумиләштерәләр. Урта баскычта өйрәнелгән темалар буенча сөйләшә белүдән тыш, Татарстанның икътисади үсеше, фәнни һәм мәдәни үсеше, халыкара элемтәләре, Россиядә һәм дөньяда тоткан урыны, Татарстанның югары уку йортлары, Татарстандагы яшьләр хәрәкәтләре турында иркен аралашуга чыгару максат итеп куела. Шулай ук укучыларны кызыксындырган, борчыган мораль проблемалар буенча да әңгәмәгә керә белүләре күзаллана. Гомумән алганда, 1-9 нчы сыйныф программасын кабатлау, программа темалары буенча сөйләмне камилләштерү күз алдында тотыла.

**Танып белү –**

Татарстан Республикасында яшәүче һәр милләт кешесе үз халкының һәм янәшәдә яшәүче башка милләтләрнең бәйрәмнәрен, традицияләрен аңларга, хөрмәт итәргә, әдәбият-сәнгать вәкилләренең иҗади казанышлары белән үзенең рухи үсешен баета алу мөмкинлегеннән файдаланырга тиеш. Татар теле өйрәнүне – “башка дөньяга тәрәзә ачу” булырлык һәм шуның аркылы укучының үз яшәешен тулырак аңлавына ярдәм итәрлек итеп оештыру зарур. Үстерү – Шәхеснең белемле булуы, тәрбиялелек һәм аның фикерләү сәләте үсеше дәрәҗәсеннән дә тора. Югары баскычта балаларның

психик үсешен фикерләүне үстерү белән бәйле психик функцияләр: логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив һәм дедуктив фикер йөртүне үстерүгә аеруча игътибар таләп ителә. Үзләштерү процессы уңышлылыгының алшарты булган универсаль уку гамәлләрен куллана белүне камилләштерү – төп максатларның берсе.

**Тәрбия –**

Укучыларның тиешле дәрәҗәдәге тәрбиялелегеннән башка укыту процессын оештыру мөмкин түгел. Шуңа күрә программа эчтәлеген сайлаганда, материалның тәрбияви мөмкинлекләре исәпкә алынды: сөйләм предметы булган әхлакый проблемалар аша укучының үзенә һәм үзенең әйләнә-тирәсендәге кешеләргә карата, тормыштагы яшәеш проблемаларына карата **шәхси кыйммәтләр формалаштыру максат итеп куелды**.

## 1. Укытуның планлаштырылган нәтиҗәләре

Күрсәтелгән максатлар нигезендә татар теле укытуның планлаштырылган нәтиҗәләре билгеләнде.

**Укытуның шәхескә кагылышлы нәтиҗәләре:**

- урта гомуми белем бирү мәктәбендә телне гамәли үзләштерү нәтиҗәсендә укучыларда татар теленең күп мәдәниятле дөньядагы роле һәм мөһимлеге турында күзаллаулар формалашу;

- татар мәдәниятенең укучылар өчен булган катламы белән танышу, башка мәдәнияткә карата ихтирам хисе уяну, аларда ватанпәрвәрлек хисе уяну;

- әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау; шәхесара һәм мәдәниятара аралашуда татар теленә карата ихтирамлы караш булдыру һәм аны яхшы өйрәнү теләге туу.

## Укытуның метапредмет нәтиҗәләре

Урта белем бирү баскычында татар теле һәм әдәбиятын укыту, танып белү чарасы буларак, укучыларның фикер йөртү, интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрен үстерүгә, шулай ук, реаль тормышта туган проблемаларны хәл итү өчен кирәк булган универсаль уку гамәлләрен (***танып белү, регулятив, коммуникатив***) формалаштыруга хезмәт итә.

**Танып белү гамәлләре:**

төп төшенчәләрне аера белү, гомумиләштерә, аналогия таба, классификация нигезләрен билгели белү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен күрә, логик нәтиҗәләр ясый белү кебек күнекмәләргә ия булу;

теләсә нинди эшчәнлектә беренче проблеманы аерып ала, аның чишелеш юлларын билгели, иң эффектив чишелеш юлын күрә белү;

үз эшчәнлегеңә рефлексия ясый, адекват бәя бирә һәм әлеге проблема чишелешен тагын да нәтиҗәлерәк итү өчен үзеңә нәрсә эшләү, нинди юнәлештә камилләшү зарурлыгын ачыклый белү; сүзлекләр, башка эзләнү схемаларын актив куллана белү сәләтләре булу;

уку һәм танып-белү мәсьәләләрен чишү өчен билге, символ, модель, схемаларны үзгәртү һәм куллана белү;

уку мәсьәләләрен чишү өчен кирәкле информацион ресурсларны ИКТ чаралары аша эзли һәм максатчан куллана белү.

**Регулятив гамәлләр:**

мөстәкыйль рәвештә максатка ирешү юлларын, шулай ук альтернатив юлларын планлаштыра белү;

уку һәм танып-белү гамәленең эффектив юлларын сайлап ала белү; үзконтроль нигезләрен яхшы белү, уку һәм танып-белү процессында үзбәя, карар кабул итүне аңлы рәвештә сайлый белү;

үз эшчәнлегеңне планлаштыруга кирәк булган фикерләреңне, хисләреңне белдерү өчен кирәк булган тел чараларын аңлы рәвештә куллана белү.

**Коммуникатив гамәлләр:**

укучының яшьтәшләре белән бердәм эшчәнлекне оештыра, парларда, индивидуаль һәм төркемдә эшли белү күнекмәсе булу;

дәлилле итеп үз фикереңне башкаларга җиткерә белү, өлкәннәр һәм яшьтәшләрең белән продуктив уртак гамәл оештыра белү;

аралашудан соң коммуникатив максатка ирешү турында бәяләмә, йомгак ясау һәм аны дәлилли белү.

## Укытуның предмет нәтиҗәләре

***Монологик сөйләм:***

- программа кысаларындагы эчтәлек буенча әңгәмәдәшеңнең сөйләмен аңлый, аңа үз карашыңны әйтә, яңа мәгълүматны чагыштыра һәм бәяли белү;

- гади һәм кушма җөмләләрне кулланып, тормышта булган хәлләр, ишеткән яңа мәгълүматлар, үзеңне борчыган проблемалар турында хәбәр итә белү;

- программада тәкъдим ителгән әхлакый проблемалар буенча үз фикереңне белдерә белү.

***Диалогик сөйләм:***

- аралашу процессында төрле репликаларны кулланып, үз фикереңне әңгәмәдәшеңә аңлата белү;

- конкрет проблема буенча әңгәмәдәшең белән бәхәсләшә һәм үз фикереңне дәлилли белү;

- программада тәкъдим ителгән проблема буенча әңгәмәдәшләрең белән иркен аралашуга чыгу.

***Тыңлап аңлау:***

- программада тәкъдим ителгән эчтәлек нигезендә төрле төрдәге тыңлап аңлау күнегүләрен үти белү; сүзләрне, җөмләләрне ишетеп тәрҗемә итә белү; зур булмаган аутентив яки адаптацияләнгән әдәби әсәрләрдән өзекләрне, мәгълүмати характердагы текстларны, вакытлы матбугат язмаларын тыңлап аңлап, эчтәлеге буенча фикер әйтү, аралашуга чыгу;

- әңгәмәдәшеңнең татарча сөйләмен тулысынча аңлау, телерадио тапшыруларны тыңлап, өлешчә аңлау.

***Уку:***

- уку текстларын татар теленең әйтелеш нормаларын саклап, сәнгатьле һәм аңлап уку;

- укыган текстның эчтәлеген логик бөтеннәргә бүлә белү, план төзи белү.

***Язу:***

- укылган әсәр, андагы проблема буенча үз фикереңне язмача җиткерә белү;

- күргән һәм ишеткән турында хикәяләп язу;

- рәсми кәгазьләрне (гариза, автобиография, характеристика, резюме) яза белү;

- әхлакый проблемага карата үз фикерләреңне язу, иҗади биремнәр үтәү.

## 2. Уку предметының төп эчтәлеге

### Сөйләмнең предмет эчтәлеге

**Белем һәм тормыш.** Киләчәккә юл сайлау. Теләк һәм мөмкинлекләр. Югары уку йортлары һәм без сайлаган һөнәрләр. Татарстан Республикасының Милли китапханәсе. Казан университетының Н.И.Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсе.

**Һөнәр сайлау.** Икътисади тормыш. Һөнәр сайлауда туган проблемалар. Яңа һөнәрләр. Без сайлаган профессияләр, аларга куелган таләпләр.

**Татарстан республикасы.** Хәзерге икътисад шартларында Татарстанның экономик, мәдәни һәм сәнгать казанышлары. Халыкара багланышлар. Халыклар дуслыгы. Татар теленең дөньякүләм урыны. Казанның тарихи һәм истәлекле урыннары. Татар халкының якты йолдызлары (композиторлар, рәссамнар, җырчылар, артистлар, шагыйрьләр, язучылар). Күренекле шәхесләр турында кыскача белешмә бирә белү. Татарстанның бөтендөнья спорт үсешенә керткән өлеше. Татарстандагы яшьләр хәрәкәтләре.

**Дуслык. Дуслар белән аралашу.** Дусларга хас уңай һәм тискәре сыйфатлар, дус була белү, дуслар белән аралашу серләре. Дуслыкта кызларның һәм егетләрнең роле.

**Беренче хисләр, гаилә кору.** Саф хисләр, беренче хисләр, аларга сак караш. Яшьләрнең үзара аралашу әдәбе. Бергә ял итү. Катнаш гаиләләр, аларның киләчәге. Балаларны ярату, саклау, ата-ананың балалар алдындагы, балаларның ата-аналар алдындагы бурычы. Ятим балалар.

### Тел чаралары һәм аларны куллану күнекмәләре

**Грамматика.**

Аерым сүз төркемнәренә хас грамматик формаларның татар һәм рус телләрендә тәңгәл килү-килмәвен белү: татар телендә исемнең род категориясе булмавы һәм аның лексик берәмлекләр белән бирелеше; 38 татар телендә исемнең тартым категориясе булуы һәм аның рус телендә бирелеше; татар телендә хикәя фигыльнең заман формаларының мәгънәви үзенчәлекләре; татар телендә фигыльнең вид категориясе булмавы һәм аның аналитик формалар белән бирелеше; татар телендә сыйфатның сыйфатланмыш белән ярашмавы; бәйлек һәм бәйлек сүзләрнең татар телендә

сүздән соң килүе; татар сөйләмендә кисәкчәләр; татар телендә саннарның һәм сыйфатларның исем янында төрләнмәве.

**Синтаксис. Пунктуация.**

Җөмләдә сүзләрне бәйләүче чараларны гамәли куллана белү. Татар телендәге хикәя җөмләнең хәбәр белән тәмамлану үзенчәлеген истә тотып, сөйләм оештыра алу. Татар җөмләсендә сөйләм яңалыгының хәбәр алдында урнашуын белү. (*Бүген безгә кунаклар килә. Кунаклар безгә бүген килә. Кунаклар бүген безгә килә*). Иярченле кушма җөмләләрнең сөйләмдә актив кулланыла торган төрләреннән файдалана алу. Язма сөйләмдә тыныш билгеләрен дөрес куя белү: ия белән хәбәр арасында сызык; җөмләнең аерымланган кисәкләре, модаль сүзләр, тиңдәш кисәкләр янында, тезмә һәм ирченле кушма җөмләләрдә тыныш билгеләре. Диалог һәм туры сөйләм янында тыныш билгеләре.

## 3. Тематик планлаштыру

| **Курс эчтәлеге, якынча сәгатьләр саны** | **Укучы эшчәнлеге төрләренә характеристика** |
| --- | --- |
| **Белем һәм тормыш. (11 сәгать).** Киләчәккә юл сайлау. Теләк һәм мөмкинлекләр. Югары уку йортлары һәм без сайлаган һөнәрләр. Татарстан Республикасының Милли китапханәсе. Казан университетының Н.И.Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсе. | - киләчәккә сайлаган юлың, теләк һәм мөмкинлекләрең, киләчәккә ничек әзерләнүең турында, югары уку йортлары һәм сайланган һөнәрләр турында сөйләшү;<br>- Казан дәүләт университеты китапханәсе, Н.И.Лобачевский исемендәге китапханә турында хәбәр итү;<br>- күптеллелек, “Телләр белгән – илләр гизгән” проблемасы буенча әңгәмә кору;<br>- “Бүгенге тормышта конкурент шәхес нинди була?” проблемасы буенча сөйләшү. |
| **Һөнәр сайлау. (11 сәгать).** Икътисади тормыш. Һөнәр сайлауда туган проблемалар. Яңа һөнәрләр. Без сайлаган профессияләр, аларга куелган таләпләр. Югары уку йортлары һәм без сайлаган һөнәрләр, аларга куелган таләпләр. | - һөнәр сайлауның җаваплылыгы турында әңгәмә кору;<br>- бүгенге икътисади тормыштагы яңа һөнәрләр, аларга төрле карашлар турында сөйләшү;<br>- бүгенге мәктәптә борчыган проблемалар, БДИ, аңа яхшы әзерләнү һәм тапшыру өчен кирәкле сыйфатлар,чаралар турында сөйләшү. |

| | |
|---|---|
| **Татарстан республикасы. Татарстанның географик урыны (12 сәгать).** Татарстанның географик урыны, табигате. Хәзерге икътисад шартларында Татарстанның экономик, мәдәни һәм сәнгать казанышлары. Халыкара багланышлар. Халыклар дуслыгы. Татар теленең дөньякүләм урыны. Казанның тарихи һәм истәлекле урыннары. Татар халкының якты йолдызлары (композиторлар, рәссамнар, җырчылар, артистлар, шагыйрьләр, язучылар). Күренекле шәхесләр турында кыскача белешмә бирә белү. Татарстанның бөтендөнья спорт үсешенә керткән өлеше. | - Татарстандагы яшьләр хәрәкәтләре. табигате турында сөйләү;<br>- хәзерге икътисад шартларында Татарстанның экономик, мәдәни һәм сәнгать казанышлары турында хәбәр итү;<br>- Татарстанда яшәүче милләтләр, Татарстанның башкаласы – Казан шәһәре, истәлекле урыннары, музейтеатрлар һәм башка ял итү урыннары турында сөйләшү;<br>- татар сәнгатенең күренекле вәкилләре турында кыскача белешмә бирү;<br>- Татарстанның бөтендөнья спорт үсешенә керткән өлеше турында сөйләшү;<br>- Татарстандагы яшьләр хәрәкәтләре турында сөйләү. |
| **Дуслык. Дуслар белән аралашу. (12 сәгать).** Дусларга хас уңай һәм тискәре сыйфатлар, дус була белү, дуслар белән аралашу серләре. Дуслыкта кызларның һәм егетләрнең роле. Кешеләрнең уңай һәм тискәре сыйфатлары, яхшы һәм начар гадәтләре. | - дус була белү өчен кирәкле сыйфатлар турында сөйләшү, фикер алышу;<br>- дуслыкның тормышта кирәклеге, аны саклый белү, дуслар белән аралашу серләре турында дәлилләр китереп сөйләү, сөйләшү;<br>- дуслыкта, мәхәббәттә кызларның һәм егетләрнең роле турында сөйләшү. |
| **Беренче хисләр, гаилә кору. (22 сәгать).** Саф хисләр, беренче хисләр, аларга сак караш. Яшьләрнең үзара аралашу әдәбе. Бергә ял итү. Катнаш гаиләләр, аларның киләчәге. Балаларны ярату, саклау, ата-ананың балалар алдындагы, балаларның ата-аналар алдындагы бурычы. Ятим балалар. | - саф хисләр, беренче хисләр, аларга сак караш турында әңгәмә кору;<br>- “Дуслык белән мәхәббәт” проблемасы буенча әңгәмә кору;<br>- “Чын хисләр, чын ярату нинди була?” дигән проблема буенча сөйләшү;<br>- дуслар белән бергә ял итү турында, дуслыкта, мәхәббәттә кызларның һәм егетләрнең роле турында сөйләшү;<br>- гаилә кору өчен кирәкле шартлар, балаларны ярату, саклау турында сөйләшү. |

**Рабочая программа курса**

**“Родной татарский язхык” 10-11 классы**

**Планируемые результаты обучения**

**10-11 классы**

Освоение программы 10-11 классов предусматривает формирование у них следующих л**ичностных результатов:**

– уважительное и доброжелательное отношение к истории, культуре, религии, традициям, языкам, ценностям народов России и народов мира; знание истории, своего края, основ культурного наследия народов России;

– развитое моральное сознание и компетентность в решении моральных проблем на основе личностного выбора, сформированность нравственных чувств и нравственного поведения, осознанного и ответственного отношения к собственным поступкам;

– сформированность ответственного отношения к учению; уважительного отношения к труду, наличие опыта участия в социально значимом труде. Осознание значения семьи в жизни человека и общества, принятие ценности семейной жизни, уважительное и заботливое отношение к членам своей семьи;

– сформированность ценности здорового и безопасного образа жизни.

Освоение программы 10-11 классов предусматривает формирование у них следующих **метапредметных результатов обучения:**

– умение анализировать объекты с целью выделения признаков (существенных, несущественных); выбирать основания и критерии для сравнения, классификации объектов; устанавливать причинно-следственные связи; строить логическую цепь рассуждений;

– умение создавать, применять и преобразовывать знаки и символы, модели и схемы для решения учебных и познавательных задач;

– умение самостоятельно определять цели обучения, ставить и формулировать новые задачи в учебе и познавательной деятельности, развивать мотивы и интересы своей познавательной деятельности;

– умение соотносить свои действия с планируемыми результатами, осуществлять контроль своей деятельности в процессе достижения результата, определять способы действий в рамках предложенных условий и требований, корректировать свои действия в соответствии с изменяющейся ситуацией;

– умение оценивать правильность выполнения учебной задачи, собственные возможности ее решения;

– владение основами самоконтроля, самооценки, принятия решений и осуществления осознанного выбора в учебной и познавательной деятельности;

– умение осознанно использовать речевые средства в соответствии с задачей коммуникации для выражения своих чувств, мыслей и потребностей для планирования и регуляции своей деятельности; владение устной и письменной речью, монологической контекстной речью;

– компетентность в использовании информационно-коммуникационных технологий.

**Предметные результаты** обучения татарскому языку по каждой изучаемой теме приводятся в тематическом планировании в графе **характеристика основных видов деятельности учащихся.**

Планируется, что при завершении программы учащийся должен владеть следующими умениями по видам речевой деятельности:

***в диалогической речи***

- умение строить диалогическую речь в пределах тем, предусмотренных программой: диалог – расспрос, диалог – предложение, диалог – обмен мнениями, смешанные диалоги;

- умение начать, продолжить и закончить разговор; умение расспрашивать с целью уточнения событий;
- умение выражать просьбу помочь, сделать что-либо;
- умение выражать несогласие, отвергать просьбу;
- умение предлагать сотрудничество;
- умение составлять модели общения с собеседником с использованием этикетных выражений;
- умение проводить беседу по предложенной ситуации с помощью опорной схемы.

Объём диалогической речи: каждый участник диалога должен произнести не менее 10 – 12 реплик.

***в монологической речи***

- умение точно выражать свои мысли в монологической речи, соблюдая орфоэпические и грамматические нормы, используя вводные слова;
- умение пересказывать содержание прочитанного текста своими словами с помощью вопросов, плана или самостоятельно;
- умение продолжить пересказ текста;
- умение рассказывать, видоизменив текст;
- умение составлять рассказ по предложенной теме, соблюдая последовательность;
- умение выразительно рассказывать наизусть стихотворения;
- умение подготовить сообщение о новостях;
- умение защитить проект по предложенной теме;
- умение подготовить презентацию.

Объём монологической речи: не менее 13 – 15 фраз. Продолжительность речи по времени: 2 – 2,5 минуты.

***в аудировании***

- понимать на слух речь учителя и одноклассников при участии в беседе, объяснять им свое мнение;
- прослушивать небольшие аутентичные тексты или адаптированные отрывки из литературных произведений, тексты информационного характера и выражать свое мнение по их содержанию.

Продолжительность текстов для аудирования по времени звучания: 1,5 – 2 минуты.

***в чтении***

- владение навыками чтения научно-популярных, официальных текстов в пределах тем, предусмотренных программой, с полным пониманием их содержания;
- умение работать с текстами, в которых содержатся таблицы, иллюстрации, наглядная символика;
- умение при чтении текста выделять нужную информацию, систематизировать, сравнивать, анализировать, обобщать, интерпретировать и изменять его содержание.

Объём текста для чтения: 400 слов (10 класс), 500 слов (11 класс).

***в письме***

-умение правильно писать слова активного пользования, указанные в программе;

- умение письменно составлять диалоги различных моделей и рассказы по предложенной теме, прагматические тексты (рецепты, объявления, афиши и т.д.), тексты эпистолярного жанра (личные и официальные письма, поздравления и т.д.);

- умение письменно выражать свои мысли по данной проблеме;

- умение продолжить предложенный текст или видоизменить его.

Объём письменной работы: 100 – 120 слов.

**Содержание учебного предмета**
**«Родной татарский язык»**
**10-11 классы**

Содержание учебного предмета отбирается с учетом интересов учащихся в соответствии с их возрастными особенностями. Оно состоит из следующих тем:

**Знание и жизнь.** Выбор жизненного пути. Желания и возможности. Высшие учебные заведения и выбранные профессии**.** Проблемы с выбором профессии. Роль изучения языков в современной экономической жизни.

Национальная библиотека Республики Татарстан. Научная библиотека имени Н.И.Лобачевского Казанского федерального университета.

**В мире профессий.** Экономическая жизнь, новые профессии. Требования к выбранным профессиям. Проблемы, волнующие молодежь.

**Республика Татарстан.** Достижения Татарстана в области экономики, культуры и искусства, образования. Межнациональное и межконфессиональное согласие и мир в Республике Татарстан. Выдающиеся личности татарского народа (композиторы, художники, певцы, артисты, поэты, писатели, просветители). Казань – политический, культурный и исторический центр. Вклад Татарстана в развитие мирового спорта. Международные связи Республики Татарстан.

**Дружба. Общение.** Положительные и отрицательные качества друзей. Умение дружить, секреты общения с друзьями. Первые искренние чувства, бережное отношение к ним.

**Семейные ценности.** Нормы взаимоотношений среди молодёжи. Ответственное отношение к созданию семьи. Современные проблемы в семейных отношениях. Обязанности родителей перед детьми, детей – перед родителями.

## Лингвистические знания и навыки

***Грамматика.***

Соответствие-несоответствие отдельных грамматических форм в татарском и русском языках: отсутствие в татарском языке категории рода имен существительных и выражение значения рода с помощью лексем; присутствие в татарском языке категории принадлежности существительных и выражение ее в русском языке; особенности временных форм глаголов изъявительного наклонения в татарском языке; отсутствие в татарском языке категории вида у глаголов и выражение этой категории с помощью аналитических форм; несогласованность прилагательных с определяемым словом; употребление послелогов и послеложных слов после слов; употребление частиц в татарском языке; несклоняемость числительных и прилагательных при употреблении с существительными в татарском языке (*өч малайда — у трех мальчиков; бишенче сыйныфта — в пятом классе; җиде баланың — у семи детей, матур бинада — в красивом здании);* несклоняемость существительных при употреблении с количественными числительными.

***Синтаксис. Пунктуация.***

Средства связи в предложении. Постпозиция сказуемого в повествовательном предложении. Наиболее активные типы сложноподчиненных предложений. Особенности расположения синтетических придаточных предложений перед главным предложением.

Знаки препинания в письменной речи: тире между подлежащим и сказуемым, знаки препинания между обособленными членами предложения, при модальных словах, между однородными членами предложения, в сложносочиненных и сложноподчиненных предложениях. Знаки препинания в диалоге и в прямой речи.

## Примерное тематическое планирование
## 10 класс (34 часа)

| Содержание курса и ориентировочное количество часов, отводимое на тему. | Характеристика основных видов деятельности учащихся (коммуникативные умения) |
|---|---|
| **Знание и жизнь. (11 часов)** Выбор жизненного пути. Желания и возможности. Роль изучения языков в современной жизни.<br>Высшие учебные заведения РТ. Национальная библиотека Республики Татарстан. Научная библиотека имени Н.И.Лобачевского Казанского федерального университета. | **Дискутировать и вести диалог-обмен мнениями** о выбранном пути в жизни, о своих желаниях и возможностях.<br>**Высказывать своё отношение** к проблеме выбора профессии.<br>**Аргументировать свои суждения** о роли изучения языков в современной жизни.<br>**Сообщать о** высших учебных заведениях, о Национальной библиотеке Республики Татарстан, о научной библиотеке имени Н.И.Лобачевского Казанского федерального университета.<br>**Участвовать в обсуждении** проблемы конкурентоспособности личности, лидерства. |
| **Дружба. Общение. (12 часов)** Положительные и отрицательные качества друзей. Умение дружить, секреты общения с друзьями. | **Вести диалог-рассуждение о** положительных и отрицательных качествах друзей.<br>**Высказывать свое мнение** об умении дружить, о секретах общения с друзьями.<br>**Аргументировать свои суждения** о настоящей дружбе. |
| **Первые искренние чувства. (11 часов)** Первые искренние чувства, бережное отношение к ним. Дружба между парнями и девушками, совместный отдых. | **Вести диалог-рассуждение о** положительных и отрицательных качествах.<br>**Высказывать свое мнение** об умении дружить, о секретах общения.<br>**Аргументировать свои суждения** о первых искренних чувствах, о бережном отношении к ним. |

## 11 класс (34 часа)

| Содержание курса и ориентировочное количество часов, отводимое на тему. | Характеристика основных видов деятельности учащихся (коммуникативные умения) |
|---|---|
| **В мире профессий. (11 часов)** Экономическая жизнь, новые профессии. Требования к выбранным профессиям. Проблемы, волнующие молодежь. | **Вести диалог об** экономической жизни страны, о новых профессиях. **Рассказывать о** требованиях к выбранным профессиям. **Аргументировать свои доводы** об ответственности за выбор профессии. **Дискутировать, высказывать своё отношение** по проблемам, волнующим молодежь. |
| **Республика Татарстан. (12 часов)** Достижения Татарстана в области экономики, культуры и искусства, образования. Межнациональное и межконфессиональное согласие и мир в Республике Татарстан. Выдающиеся личности татарского народа (композиторы, художники, певцы, артисты, поэты, писатели, просветители). Казань – культурный и исторический центр. Вклад Татарстана в развитие мирового спорта. Международные связи Республики Татарстан. | **Сообщать, вести диалог** о достижениях Татарстана в области экономики, культуры и искусства, образования. **Рассуждать и высказывать свое мнение о** межнациональном и межконфессиональном согласии в Республике Татарстан. **Вести диалоги** о выдающихся личностях татарского народа (композиторах, художниках, певцах, артистах, поэтах, писателях, просветителях). **Охарактеризовать** Казань как культурную и спортивную столицу России. **Донести информацию через диалог** о международных отношениях РТ. |
| **Семейные ценности. (11 часов)** Нормы взаимоотношений среди молодёжи. Совместный отдых. Ответственное отношение к созданию семьи. Современные проблемы в семейных отношениях. Обязанности родителей перед детьми, детей – перед родителями. Сироты. Детские дома. | **Вести беседу о** пробуждении первых чувств, о бережном отношении к ним, об ответственности каждого за сохранность чувств. **Обсуждать проблему** настоящей любви, семейных ценностей. |

**Учебно-тематическое планирование**
**10 класс**

| № | Тема раздела<br>Тема урока | Количество часов |
|---|---|---|
| | **Знание и жизнь. (11 часов)**<br>**Белем һәм тормыш (11 сәгать)** | |
| 1 | Знание и жизнь. Прямая речь.<br>Белем һәм тормыш. Туры сөйләм. | 1 |
| 2 | Категория принадлежности существительных.<br>Исемнәрнең тартым белән төрләнеше. | 1 |
| 3 | К.Насыри “Книга о воспитании”. Формы глаголов изъявительного наклонения (повторение).<br>К.Насыйри “Тәрбия китабы”. Хикәя фигыль (кабатлау) | 1 |
| 4 | Словообразование существительных.<br>Исемнәрнең ясалышы. | 1 |
| 5 | Научная библиотека имени Н.И.Лобачевского Казанского федерального университета.<br>Казан дәүләт университетының Н.И.Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсе. | 1 |
| 6 | Высшие учебные заведения РТ.<br>Казандагы югары уку йортлары. | 1 |
| 7 | Использование разрядов числительных в речи.<br>Сан төркемчәләрен сөйләмдә куллану. | 1 |
| 8 | Где проживают татары?<br>Татарлар кайларда яшиләр? | 1 |
| 9 | Контрольная работа на тему “Самостоятельные части речи”.<br>**Контроль эш.** “Мөстәкыйль сүз төркемнәре”. | 1 |
| 1 | Беседа о роли изучения языков в современной жизни.<br>“Телләр белгән – илләр гизгән” проблемасы буенча әңгәмә. | 1 |
| 1 | Обсуждение по проблеме конкурентоспособности личности, лидерства.<br>Бүгенге тормышта конкурент шәхес нинди була? | 1 |
| | **Дустың булмаса – эзлә, тапсаң – сакла (12 сәг.)**<br>**Дружба. Общение. (12 часов)** | |
| 1 | Словообразование глаголов.<br>Фигыль төзелеше. | 1 |
| 1 | Мой друг, моя подруга.<br>Минем дустым | 1 |
| 1 | Послелоги и послелоңные слова.<br>Бәйлек һәм бәйлек сүзләр. | 1 |
| 1 | Конструкция инфинитив + *тиеш, мөмкин, кирәк, ярый.* | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| | Инфинитив + *тиеш, мөмкин, кирәк, ярый.* | |
| 1 | Аудирование “Берегитесь от вредных привычек!”<br>Тыңлап аңлау “Начар гадәтләрдән сакланыгыз!” | 1 |
| 1 | Стиль деловых бумаг. Доверенность.<br>Эш кәгазьләре стиле. Ышаныч кәгазе. | 1 |
| 1 | Диалог “Жить по-современному”.<br>Диалог “Заманча яшәү”. | 1 |
| 1 | Аналитические формы глагола.<br>Тезмә фигыльләр. | 1 |
| 2 | Глагол изъявительного наклонения незавершенном прошедщего времени.<br>Тәмамланмаган үткән заман хикәя фигыль. | 1 |
| 2 | **Контрольная работа** на тему “Глагол”.<br>**Контроль эш**. “Фигыль”. | 1 |
| 2 | Проводим праздники с друзьями.<br>Дуслар белән бәйрәмнәр уздыру. | 1 |
| 2 | Диалог на тему “Секреты дружбы”.<br>Диалог ”Дус була белү серләре”. | 1 |
| | **Первые искренние чувства. (11 часов)**<br>**Саф хисләр, беренче хисләр (11 сәгать)** | |
| 2 | Формы деепричастия.<br>Хәл фигыль формалары. | 1 |
| 2 | Виды предложений. Простое и сложное предложение.<br>Җөмлә төрләре. Гади һәм кушма җөмләләр | 1 |
| 2 | Стиль деловых бумаг. Письмо.<br>Эш кәгазьләре стиле. Хат. | 1 |
| 2 | Сложносоченённые предложения.<br>Тезмә кушма җөмлә. | 1 |
| 2 | Виды сложноподченённых предложений с придаточными обстоятельства.<br>Иярчен хәл җөмләләрнең төрләре. | 1 |
| 2 | Какие мне нравятся девушки (парни)?<br>Миңа нинди кызлар (малайлар) ошый? | 1 |
| 3 | Сложноподченённые предложения с аналитическими и синтетическими строениями.<br>Иярченле кушма җөмләләрнең аналитик һәм синтетик төрләре. | 1 |
| 3 | Проект на тему “Моя семья в период войны”.<br>Проект. Сугыш чорында минем гаиләм. | 1 |
| 3 | **Контрольная работа** на тему “Сложное предложение”.<br>**Контроль эш.** “Кушма җөмлә” | 1 |
| 3 | Секреты одевания.<br>Дөрес киенү серләре | 1 |
| 3 | Идеальные девушки, идеальные парни. | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| | Идеаль кызлар, идеаль егетләр | |
| | **Всего:**<br>**Барлыгы:** | **34 часа**<br>**34 сәг.** |

**Учебно-тематическое планирование**
**11 класс**

| № | **Тема раздела**<br>**Тема урока** | **Количество часов** |
|---|---|---|
| | **В мире профессий. (11 часов)**<br>**Һөнәрләр дөньясында (11 сәгать)** | |
| 1 | Временные формы глагола изъявительного наклонения.<br>Хикәя фигыльнең заман формалары. | 1 |
| 2 | Изучение членов предложения.<br>Җөмлә кисәкләрен өйрәнү. | 1 |
| 3 | Падежи. Склонение имён сущиствительных по падежам. **Словарный диктант.**<br>Килешләр. Исемнәрнең килеш белән төрләнеше. **Сүзлек диктанты.** | 1 |
| 4 | Спряжение по лицам и числам глагола желательного наклонения.<br>Теләк белдерү формасының зат-сан белән төрләнеше. | 1 |
| 5 | Временные формы причастия.<br>Сыйфат фигыльнең заман формалары. | 1 |
| 6 | Глагол условного наклонения.<br>Шарт фигыльне өйрәнү. | 1 |
| 7 | Отрицательная форма глагола изъявительного наклонения.<br>Хикәя фигыльнең юклык формасы. | 1 |
| 8 | Деепричастие, причастие.<br>Хәл фигыль, сыйфат фигыль. | 1 |
| 9 | Словообразовательные аффиксы. Словообразовательные аффиксы прилагательных.<br>Сүзъясагыч кушымчалар. Сыйфат ясагыч кушымчалар. | 1 |
| 10 | Склонение по падежам личных местоимений. **Словарный диктант.**<br>Зат алмашлыкларының килеш белән төрләнеше. **Сүзлек диктанты.** | 1 |
| 11 | Формы деепричастия.<br>Хәл фигыль формаларын өйрәнү. | 1 |
| | **Республика Татарстан. (12 часов)**<br>**Татарстан республикасы (12 сәгать)** | |
| 12 | Послеложные слова.<br>Бәйлек сүзләрне өйрәнү. | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| 13 | Конструкция прилагательное+существительное.<br>Сыйфат+исем конструкциясе. | 1 |
| 14 | **Контрольная работа** на тему “Формы глагола”.<br>**Контроль эш**. Фигыль формалары. | 1 |
| 15 | Работа над ошибками. Словообразовательные аффиксы.<br>Хаталарны төзәтү өстендә эш. Сүзъясагыч кушымчалар. | 1 |
| 16 | Отрицательная форма глагола изъявительного наклонения.<br>Хәзерге заман хикәя фигыльнең юклык формасы. | 1 |
| 17 | Тире между подлежащим и сказуемым.<br>Ия белән хәбәр арасында сызык. | 1 |
| 18 | Конструкция существительное+существительное. Изафетные сочетания. **Словарный диктант.**<br>Исем+исем конструкциясе. **Сүзлек диктанты.** | 1 |
| 20 | Склонение существительных с аффиксами принадлежности. Упражнения на закрепление.<br>Исемнәрнең тартым белән төрләнеше. Ныгыту күнегүләре. | 1 |
| 21 | Разряды числительных. Словообразование и правописание числительных.<br>Сан төркемчәләре, санның ясалышы, язылышы. | 1 |
| 22 | Разряды местоимений.<br>Алмашлык төркемчәләре. | 1 |
| 23 | Спряжение по лицам и числам глагола будущего определённого времени изъявительного наклонения.<br>Билгеле киләчәк заман хикәя фигыльнең зат-сан белән төрләнеше. | 1 |
| | **Семейные ценности. (11 часа)**<br>**Гаилә кыйммәтләре (11 сәгать)** | |
| 24 | Использование в разных падежных формах послеложных слов.<br>Бәйлек сүзләрнең төрле килешләрдә кулланылышы. | 1 |
| 25 | Спряжение по лицам и числам глагола будущего неопределённого времени изъявительного наклонения.<br>Билгесез киләчәк заман хикәя фигыльнең зат-сан белән төрләнеше. | 1 |
| 26 | Разряды наречий.<br>Рәвеш төркемчәләре. | 1 |
| 27 | **Самостоятельная работа.** Разряды наречий.<br>**Мөстәкыйль эш.** Рәвеш төркемчәләре. | 1 |
| 28 | Нераспространенные и распространенные предложения. Виды предложений по цели высказывания.<br>Җыйнак һәм җәенке җөмләләр, әйтелү максаты ягыннан җөмлә төрләре. | 1 |
| 29 | Частицы.<br>Кисәкчәләр. | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| 30 | Имя действия.<br>Исем фигыль. | 1 |
| 31 | Инфинитив. **Словарный диктант.**<br>Инфинитив. **Сүзлек диктанты.** | 1 |
| 32 | Спряжение по лицам и числам глагола повелительного наклонения.<br>Боерык фигыльнең зат-сан белән төрләнеше. | 1 |
| 33 | **Годовая контрольная работа.** Послеложные слова.<br>**Еллык контроль эш.** Бәйлек сүзләр. | 1 |
| 34 | Союзы.<br>Теркәгечләр. | 1 |
| | **Всего:**<br>**Барлыгы:** | **34 часа**<br>**34 сәг.** |

**Нормы контроля обученности по видам речевой деятельности**
**10-11 классы**

| № | Виды речевой деятельности | Классы | |
|---|---|---|---|
| | | **10** | **11** |
| 1. | Аудирование | 1,5-2,0 минуты | 2-2,5 минуты |
| 2. | Диалогическая речь | 11-12 реплик | 13-14 реплик |
| 3. | Монологическая речь | 10-12 фраз | 12-14 фраз |
| 4. | Чтение | 95-100 слов | 95-100 слов |
| 5. | Письмо: | 10-15 фраз | 15-20 фраз |
| | словарный диктант | 25-27 слов | 28-30 слов |
| | сочинение | 12-15 предложений | 13-15 предложений |